УРТАК БӘЛА

Татарстан Дәүләт Советы утырышында сукбай этләр мәсьәләсе каралды

> 2

АВЫЛ ӨМЕТЕ

Балтач районының «Татарстан» хуҗалыгында яшь белгечләргә кытлык юк

> 2

ЯГЪФӘР ШӘМИЕВ:

«Спортчылар бар ул, физик тәрбия бирүчеләр генә җитешми»

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 34 (28807) | Шимбә | 12 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ТАПШЫРЫЛМАГАН БАСМАЛАР

Вазгыять

Язылган газеталар өйгә килми, чөнки таратырга хат ташучы юк. Шәһәрдә абунәче әби-бабайлар атна саен почта юлын таптарга мәҗбүр. Почтальоннарның биштәрендә исә басма матбугат урынына – чәй, шикәр, май. Алар шуны сатып, үзләренә хезмәт хакы эшләргә мәҗбүр. Хат ташучылар кайчан алыпсатар булудан туктар? Газетаны китермәсәләр, үз хокукларыбызны ничек якларга? «ВТ» хәбәрчесе ияләренә тапшырылмаган басмалар, хат ташучылар проблемалары турында кызыксынды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Эшләргә кеше юк

Авылларда элек хат ташучыларны көн саен сагынып көтеп ала идек. Табадан төшкән газетаны кулга алу үзе бер бүләк иде. Хәзер почтальоннар сирәк күренә. Халык белән иркенләп сөйләшергә дә вакытлары юк. Вакытында таратылмагач, газеталарның да кызыгы бетә, тәме калмый. Искергән ризыкны ашарга теләмәгән кебек, соңарып килгән матбугатка да кешенең әллә ни исе китми. Хат ташучылар җитми, дигән проблеманы да еш ишетергә туры килә. Хезмәт хакы кечкенә, эше күп дип, бу хезмәткә килергә бик атлыгып тормыйлар.

Бер көнне редакциягә Вишневский урамында яшәүче ирле-хатынлы 82 яшьлек Флера әби белән 88 яшьлек Нәсхәт бабай килде.

– «Ватаным Татарстан» газетасын күптән түгел алдыра башладык. Соңгы вакытта хат ташучы китерми, үзебез почта бүлекчәсенә барып алабыз. Тик һаман саен болай йөрү туйдыра. Тайгак юлларда хәтәр. Болай булса, газетадан баш тартасы булыр инде. Безне газетадан биздермәсеннәр иде. Проблеманы хәл итәргә булышыгыз әле, – дип үтенде Габделхәевләр.

Ә проблема шул ук – эшләргә кеше юк. Дөрес, «Татарстан почтасы»ның матбугат үзәге мәгълүматларына караганда, республикада почта бүлекчәләрен хезмәткәрләр белән тәэмин итү 95,8 процентны тәшкил итә. 2022 елның гыйнварында «Россия почтасы» чираттагы тапкыр минималь окладларны арттырган. Татарстанда исә уртача хезмәт хакы 7,8 процентка арткан. Россия буенча үзгәрешләр 136 мең кешегә кагылса, шуларның 65 проценттан артыгы – почтальоннар, операторлар һәм хатларны аралаучылар. Шулай ук почтальоннар азык-төлек һәм башка товарлар саткан өчен акчалата премия ала.

Киләләр дә китәләр...

Элек хат ташучылар күбрәк җәяү йөрсә, бүген күбесе машинада йөри. Техникасы булмаганнарын ирләре илтә. Әтнә районына командировкага баргач, Рәзинә Әхмәдуллина кышын иренең почтаны берничә хуҗалыклы авылга тракторда илтүен әйткән иде. Юл булмагач, башка чара юк.

Республика авылларының берсендә хат ташучы Раилә ханымга да ике авыл арасын сигез ел җәяү таптарга туры килгән. Хәзер лаеклы ялга чыккан ире булыша. Ул булмаса, дүртәр биштәр асып йөрүгә түзәрлек түгел, аяклар авырта, ди. Әле дә шул кредит түләп бетергәнче дип кенә сабыр итүе.

– Эше күп, – ди ул. – Элек газеталар белән танышырга вакыт тия иде, хәзер матбугатта нәрсә язылганын да белмибез. Әбиләр дә сагынып көтеп тора, тик алар белән аралашырга вакыт калмый. Ишектән ук кебек атылып керәбез дә чыгып китәбез. Дөрес, атнага өч тапкыр эшлибез. Өйдән иртән сәгать 9да чыгып китәм, ярты тәүлектән кире әйләнеп кайтам. Пенсия өләшү күп вакытны ала. Әбиләр, берүк эшли генә күр инде, диләр. Кеше газетага аз язылса да, хат ташучыларга эш кимеде дигән сүз түгел бу. Бер урам башында – хат, икенчесендә газета көтеп торалар. Шулай булгач, урамны барыбер узасы. 0,8 ставкага эшлим, аена 11 мең сум тирәсе акча алам.

Биштәрләренә газета, пенсия акчасын гына түгел, тәмәкесен, чәен, токмачын да тутырып йөри алар. Шулай ук тузан суырткыч, телевизор, суыткыч сатучылар да бар. Чын-чынлап сәүдәгәргә әйләнеп беткәннәр түгелме соң?

Товар сату Чирмешән районы хат ташучыларының да үзәгенә үткән. Әнә шуңа күрә Кармыш авылында күздән бирле почтальон таба алмыйлар. Монда 321 кеше яши.

Авыл җирлеге башлыгы Илдар Фәтхетдинов әйтүенчә, берәү дә почта таратырга ризалашмый. Ник дигәндә, төп эшеңнән тыш айга 65 мең сумлык товар сатарга кушалар, ә почтальоннар шуны тутыра алмыйбыз дип зарлана.

– Кармышта почта бүлегендә хат таратучы юк. Әлегә Яшәүче һәм Әккәрәй авылларының хат ташучылары кармышлыларның газеталарын кабул итеп ала, пенсияләрен тапшыра. Газета, квитанцияләрне үзең барып алырга кирәк, – ди Илдар Фәтхетдинов.

Лениногорск районының Урмышлы авылы җирлеге башлыгы Артур Хәбибуллин да хат ташучылардан алыпсатар ясау белән килешми. Продукция сатсаң – бер, сатмасаң, икенче төрле хезмәт хакы аласың. Аның әйтүенчә, хат ташучы 6–7 мең сум хезмәт хакы ала, продукция сатса, премия бирәләр. Хезмәт хакларын арттырсалар, эшләргә теләүче булачак, әлбәттә. Әлегә монда почта җитәкчесенә өч авылга газеталар да илтергә туры килә. Калган өч авылда өлкәннәр пенсияләрен банк аша ала, газета укучы юк.

Баулы районының Кызыл Яр авылы почта бүлеге начальнигы Зөлфирә Тәхаветдинова да, хат ташучылар гел алышынып тора, ди. «Узган ел өч хат ташучы урынына ике ай ике кеше генә эшләде. Яшьләрне алган идем, күпмегә түзәрләр? Хәзер өч хат ташучы бар», –диде Зөлфирә Тәхаветдинова.

Ахыры 2 нче биттә >

Документ эше гадиләшә

Дәүләт Думасы санкцияләр шартларында төзелеш тармагына ярдәм итү өчен кайбер эшләрне гадиләштерү турында закон проектын беръюлы өч укылышта кабул иткән. Бу хакта ТАСС хәбәр итә. Иң элек күчемсез милекне дәүләт кадастр исәбенә кую һәм аңа хокукны теркәү өчен документларга экспертиза уздыру эше гадиләштерелә. Мәсәлән, су басу зоналары яки су саклау зоналары чикләрендәге корылмаларның су басу ихтималыннан саклау җиһазлары белән тәэмин ителү-ителмәвен тикшерү юкка чыгарыла. Моннан тыш, төзелгән объектларга хокукны теркәү җиңеләйтелә. Шулай ук шәһәр төзелеше документларын эшләү һәм килештерү, проектлар буенча җәмәгать тыңлаулары уздыру, капиталь төзелеш объектларын төзү гадиләштерелә.

Тагын бер яңалык: дәүләт милкендәге җир кишәрлеген арендага алып торучылар аренда килешүен, торглар уздырмыйча гына, 2023 елның 1 мартына кадәр озайтуны таләп итә алачак.

Һава юллары ачыла

Россия 9 марттан 8 илгә самолет рейсларын яңартып җибәрде. Сүз Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан һәм Иран турында бара. Росавиация матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, әлеге илләргә очу һава юллары турында хөкүмәтара килешүләр һәм авиация оешмаларының аерым килешүләре нигезендә хәл ителәчәк.

Чикләүләрнең COVID-19 инфекциясе таралуга бәйле рәвештә кертелгәнлеген искәртик.

worldskills2019.com

Алтын бәһасе

Соңгы атналарда Россиядә алтын һәм палладийга ихтыяҗ 4 тапкыр арткан. Кыйммәтле металлга карата кызыксынуның артуы, әлбәттә инде, аның бәясе үсүгә китерә. Саклык банкы хәбәр иткәнчә, алтын 11 гыйнвардан 10 мартка кадәр 70 проценттан күбрәккә кыйммәтләнгән. Алтынлы булырга теләүчеләрнең ишәюе банктан кыйммәтле металл коелмалары сатып алуга (физик затлар турында сүз) салымны юкка чыгаруга бәйле. Банклар кешеләрдән алтын сатып алганда да салым түләнми.

Саклык банкы белгече Сергей Широков сүзләренә караганда, алтын коелмасы акчаны саклауның яхшы ысулы булып тора. Кыйммәтле металл сатып алуга 20 процент күләмендәге НДСны юкка чыгару нәтиҗәсендә металл хакы арзанайган – элек бер килограмм коелма 10 мең сум торса, хәзер аның бәясе 8 мең сум тәшкил итә. Алтын, көмеш, агалтын һәм палладий коелмаларын банк офисларында, коелма һәм инвестицион монета рәвешендә, шулай ук, металлны кулга алмыйча, металл счетлары ачу нигезендә сатып алырга мөмкин.

Көн кадагында

Үзеңнеке – үзәктә

Россия Президенты Владимир Путин катнашында Хөкүмәт йортында узган киңәшмәнең буеннан-буена әнә шул фикер яңгырады. «Чит ил инвесторлары китүдән безнең җитештерүчеләр зыян күрергә тиеш түгел», – дип белдерде ил башлыгы.

Россия Премьер-министры Михаил Мишустин сүзләренә караганда, икътисадтагы вазгыятькә тәүлек әйләнәсе күзәтчелек ителә. Бу юнәлештә эш алып баручы махсус штаб та булдырылган. «Бүген безнең төп бурыч эчке базарны саклау, оешмаларның өзлексез эшләвен, эш урыннарын саклап калудан гыйбарәт», – ди Мишустин. Куелган максатларга ирешү өчен, 20 закон проекты әзерләнгән.

Сүз уңаеннан, Татарстанның барлык муниципаль берәмлекләрендә һәм министрлыкларда да икътисадны тотрыклы үстерү өчен махсус оператив штаблар эшли. Бу хакта журналистларга Татарстанның икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов хәбәр итте. Оператив штаб Татарстан Президент Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча төзелгән. Аңа Премьер-министр Алексей Песошин җитәкчелек итә. Оператив штаб кибетләрне азык-төлек һәм башка товарлар белән тәэмин итү, төп оешмаларга, эшмәкәрләргә булышу, шулай ук эшмәкәрлекнең банклар белән хезмәттәшлеге буенча чаралар күрә.

Мидхәт Шаһиәхмәтов сүзләренә караганда, эш төркеменең чираттагы утырышында импортны алыштыру мәсьәләсе буенча фикер алышканнар. Татарстан оешмаларында моңарчы чит илдән кертелгән продукция аналогларын җитештерү мөмкинлекләре дә каралган. «Ведомствоның төп бурычларының берсе оешмаларның дәүләт программаларында катнашуын тәэмин итүдән

гыйбарәт. Илдә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча барлык чараларны тормышка ашыруга акча тулысынча бирелгән», – диде министр.

Тулысынча диммәктән, Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә илдәге барлык сәүдә челтәрләре дә кирәкле азык-төлек белән тулысынча тәэмин ителгән, дип тынычландырдылар. «Соңгы берничә көндә халык кибетләрдән күпләп, хәтта артыгы белән азык-төлек җыя. Ярма, шикәр комы, токмач, консерв, онга ихтыяҗ аеруча зур. Шуңа күрә без, иң беренче чиратта, кибет киштәләренә товарның өзлексез килеп торуын тәэмин итәргә тиеш», – дип белдерде Россиянең сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров.

Бу мәсьәлә республика күләмендә дә контрольдә. Сүз уңаеннан, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе бу көннәрдә бәяләр үсү мәсьәләләренә кагылышлы «кайнар элемтә» ачкан. Аңа теләсә кем мөрәҗәгать итә ала. Хәбәрләрне кабул итү ФАСның Татарстандагы идарәсе белгече Эмиль Гыйбадуллинга йөкләнгән. Элемтәгә керү өчен телефон: 8 (843) 238-30-59.

Сүзгә-сүз

Айрат ФӘРРАХОВ, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

Россия икътисадына каршы игълан ителгән «санкцияләр сугышы» барганда, мине, табиб буларак, дару җитештерүче чит ил предприятиеләре язмышы борчый. Белүемчә, аларның күбесе эшләрен дәвам иттерергә риза. Шуңа күрә халыкны чит ил дарулары белән тәэмин итүдә өзеклек кимесен өчен, мөмкин булган чараларны куллану кирәк.

(«Инстаграм» сәхифәсеннән)

РОССИЯДӘ – СПОРТ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮ

Илкүләм фитнес җәмгыяте Россия халкыннан фитнес, спортка мөнәсәбәте турында сорашкан. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, коронавирус чикләүләре кимегәч, спорт залына йөрүчеләр арткан.

85%	фитнес-клубка яңадан йөри башлаган
70%	фитнес белән онлайн шөгыльләнгән
38%	пандемия вакытында өйдә шөгыльләнгән

Эшләгәнгә эш табыла

Февраль аенда Татарстанда буш эш урыннары саны 40 процентка арткан. HeadHunter бастырып чыгарган мәгълүматлар шул хакта сөйли.

Республикада эш бирүчеләрнең активлыгы тулаем илдәгегә караганда шактый ук үскән. Россия күләмендә вакансияләр саны узган елдагы белән чагыштырганда 26 процентка гына арткан. Хәзерге вакытта Татарстанда чимал чыгару, төзелеш, күчемсез милек, спорт һәм фитнес өлкәләре белгечләренә, эшче кулларга ихтыяҗ зур. Ә менә автомобиль бизнесы, туризм, кунакханә, ресторан-кафелар һәм банклар, киресенчә, белгечләр штатын кыскартырга мәҗбүр.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Гаделсезлек һәм геометрия

Кайда гына эшләсәк, яшәсәк тә, без һәрвакыт кемгә булса да буйсынабыз, безнең белән кем булса да идарә итә. Авылда булсаң, син җигелгән арбаның дилбегәсе күмәк хуҗалык җитәкчесе йә шунда бригадир вазыйфасындагы берәр зат кулында икәнен күрәсең. Предприятие эшчесе икәнсең, син мастер белән цех башлыгының кубызына биисең, алар алдында хисап тотасың. Инженер булсаң, синең «өстә» бүлек башлыгы, бүлек башлыгы булсаң, акыл өйрәтергә баш инженер, директор бар. Аларның, ул кешеләрнең өстендә дә, үз чиратында, тагын кырыкмаса-кырык башлык, түрәләр. Иң югары җитәкчегә кадәр барысы да баш, барысы да түш.

Мондый баскычта, мондый иерархиядә, элек-электән олы бер гаделсезлек яшәп килә. Зурдан алганда, өстәгеләрне туйдырып торган, аларга хезмәт иткән, ләкин өстәгеләр белән чагыштырганда гадәттә начаррак яшәгән, нужаны күбрәк күргән катлау – пирамиданың һәрчак иң-иң астында. Электән, борынгыдан килгән традиция бу. Аның асылында антик чорда плебс дип кимсетелгән шул катлауның бүгенгәчә, шушы XXI гасыргача бетмәгән хокуксызлыгы ята. Хокук һәм мөмкинлекләрнең чикләнгән булуы. Пирамиданың югары катына, очына менгәннәрнең һәрчак шул «плебс»ның язмышы белән уйнавы, рәхимсезлеге. Квинт Гораций ике мең ел элек язган формула, бөтен дөньясында дип әйтеп булмаса да, хәтсез тарафларда әле дә саклана: «Патшаларның акылсыз дуамаллыгы халыкка һәрчак михнәт китерә».

Илбашы (патша, генсек, президент), аның яраннары. Үтә байлар, югары түрәләр һәм генералитет. Хакимнәр белән бер сүздәге дин әһелләре. Идеология һәм пропаганда аппараты. Ваграк түрәләр. Эчке тәртип сагында торучы милиция яки полиция. Гади халык. Классик пирамиданы якынча шулайрак сурәтләп булыр иде. Күрүебезчә, пирамиданың очыннан аның нигезенә кадәр ара шактый. «Тәхет»тәге зат шәфкатьле, кешелекле булган тәкъдирдә дә халык янына төшеп җиткәнче, аның моң-зарын ишеткәнче, баскыч өстендә баскыч, түрә өстендә түрә. Хәтта демократик саналган җәмгыятьләрдә дә андый субординациядән котыла алмыйлар. Элекке дәверләрдә исә падишаһлар гомумән дә «аска төшеп» тормаган. Гаделлек бөтенләй булмаган ул чорларда тәхет хуҗасы еш кына чынбарлык белән ялгыш та кисешмәгән параллель дөньяда гомер иткән. «Халык ачлыктан интегә бит» диюгә: «Ник соң алар пылау ашамый?» ише мәзәкләр нәкъ шундый чакларда туган да.

Барыбыз да белгән геометрик фигура хакында сөйләшкәндә, шул җәһәттән, тагын бер якны искәртәсе килә: пирамида зуррак, кәнәфи биегрәк булган саен гавам кадерсезрәк. (Моңа мисал – үз халкының җелеген суырып, башкаларны тинтерәтеп яшәгән империяләр). Халык күптә җаваплылык зуррак булырга тиеш тә бит югыйсә. Чынлыкта, иң югары тәхет ияләре, миллионнар язмышы белән уйнап та, еш кына беркем алдында да җавап тотмаган. Тарихта моңа мисаллар бихисап. Илләрнең бер кеше яисә тар даирә акылы белән яшәп, миллионнар фикере исәпкә алынмау – кешелекнең бүген дә гамәлдән чыгып бетмәгән гаҗизлеге, аның олы бәлаләренең берсе.

Тик бүгенге дөньяны бөтенләй өметсез дип тә булмый. Халык арасында йөргән патшалар, гади кешедән вазыйфасы, җилкәсендәге җаваплылыгы белән генә аерылган, эшкә велосипед белән йөргән мэр, премьерлар да юк түгел. Хәтсез еллар элек урамда ике-өч кешелек каһвә чиратына баскан Финляндия президенты турында язган идем. Андый башлангычлар күбрәк күзәтелсә, власть пирамидасы хакында сүз куерту бик үк урынлы да булмас иде.

Аптыраган үрдәк күлгә арты белән чума, ди. Пирамидалар, алар тудырган гаделсезлекне уйлап баш каткач, яңадан тарихка кереп китеп, анархия теориясе авторлары карашыннан, теләсә нинди хакимиятне явызлыкка тиңләгән, алардан кичекмәстән ваз кичәргә өндәгән Бакунин, Кропоткин, Прудон хезмәтләреннән рациональ уй сөреше, мантыйк, хаклык табасы килгән чаклар да була. Хаклык күпмедер күләмдә аларда да бардыр, бәлки. Чөнки анархизм тәгълиматы да буш урында тумаган. Хакимнәрнең һич кичермәслек гөнаһлары аркасында яралган ул агым. «Власть – зло. Абсолютная власть – абсолютное зло» анархистлар уйлап тапкан билгеләмә түгел микән? Әмма хакимиятсез, идарәсез дә әллә кая китеп булмый. Барысы да хакимият сыйфатына, аның ипле һәм мәгънәле яисә затсыз һәм мин-минлекле булуына барып тоташа, дию дөресрәк.

Анархия дип без бүген соң дәрәҗәдәге тәртипсезлекне атасак, халык идарәсен аңлаткан демократия дә бар бит әле. Тик демократик дәүләт төзелеше дә гаделсезлектән, чирдән коткаручы универсаль дару – панацея түгел. Американы демократик илләр рәтенә кертәләр. Ләкин ул кодрәтле илнең гади халкына кирәк идеме Вьетнам, Әфганстан, Ирактагы, Ливиядәге сугыш, АКШтан бик еракта, дөньяның икенче ягында урнашкан ул илләрдән кайткан табутлар? Гади халыкның АКШта да хаҗәтләре гади: тыныч тормыш, күңелгә яткан эш, торак, балалар үстерү, сәламәтлек…

Пирамида – нигезе киң геометрик фигура, тотрыклы һәм дә ишелүгә бирешмәүчән. Мисыр пирамидалары да тәккә генә өч мең ярым ел буе тормый. Гасырлардан килгән власть пирамидасы, аның затсыз вариантларын да кертеп, җир йөзендә әлегә кала килә. Алар исәнлеге беренче чиратта халыктагы таркаулыкка, куркуга, пассивлыкка барып тоташа. Адәми затларның үзара теләктәш булырга, бергәләп эш итәргә, аң-белемгә ирешергә атлыгып тормавына. Төрле вертикальләргә, пирамидага альтернатива, мәгълүм ки, күпсанлы горизонталь бәйләнешләр, халыкның активлыгы, булдыклылыгы, үҗәтлеге, дәүләт белән идарә итүдә катнашуы. Ягъни мәсәлән, тулы канлы гражданлык җәмгыяте.

Дәүләт Советында

БӘЛА ДӘ, ҖАВАПЛЫЛЫК ТА

tatarstan.ru

6,8 мең мөрәҗәгать. Былтыр республиканың медицина оешмаларына, эт тешләүдән зыян күреп, шулкадәр кеше килгән. «Алдынгылар» рәтендә – Югары Ослан, Спас, Лаеш районнары. Биектау, Әтнә районнарында да зарланучылар саны бермә-бер арткан.

Социаль челтәрләрдә дә бу сорау еш кузгатыла. 2020 ел белән чагыштырганда, анда да мөрәҗәгатьләр саны 42 процентка күбәйгән. Дәүләт Советы Президумының күчмә утырышында хайваннар белән җаваплы эш итүгә кагылышлы законнарның үтәлеше турында сөйләштеләр.

– Илнең күп кенә төбәкләре, халкы өчен хуҗасыз хайваннарны тоту проблемасы кискен тора. Бу мәсьәлә республика җитәкчесен дә, депутатларны да, районнардагы хезмәттәшләребезне дә борчый, – диде бу җәһәттән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Сүз уңаеннан, Президиум утырышына кадәр депутатлар йортсыз-хуҗасыз этләр өчен приютта булып кайтты. Билгеле булганча, бинаны өч ел элек төзекләндергәннәр иде. Хәзер биредә барлыгы 1500 урынлык ике корпус эшли, блоклар яңартылган, махсус мәйданчыклар барлыкка килгән. Мал табибы хезмәтеннән дә файдаланырга була: көн саен 15ләп хайванны кабул итәрлек мөмкинлек бар.

«Зооцентр» җәмгыяте директоры Рөстәм Нуруллин әйтүенчә, приютта шәхси хуҗалыклардан югалган хайваннарны кире кайтару эше дә алып барыла. Әлеге бинаны яңарту эшләре һаман дәвам итә. Алга таба биредә 2 меңләп хайванны асрау мөмкинлеге булачак. Бу елның сентябрь аенда мәктәп балалары һәм теләге булган кешеләр катнашында тематик очрашулар үткәрү өчен лекция залы эшли башлаячак.

Президиум утырышында күтәрелгән сукбай хайваннар мәсьәләсенә кире кайтып, былтыр районнарга бу юнәлештә эш башкару өчен 56,7 млн сум акча бүлеп бирелгәнен искәрттеләр. Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Алмаз Хисаметдинов әйтүенчә, хуҗасыз 11,6 мең хайван тотылган. Быел бүленеп бireләчәк акчаны арттырганнар (69,3 млн сум).

Идарә башлыгы искәрткәнчә, сукбай этләрне тоту белән махсуслашкан оешма шөгыльләнергә тиеш. Дәүләт биргән акча исә приюттагы этне асрауга, дәвалау чараларына, вакцина ясату, тамга тагу, стерильләштерүгә, яраксыз хайваннарны махсус рәвештә йоклатуга киткән чыгымнарны үз эченә ала.

Башкаланың да баш бәласе булган мәсьәлә турында Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Искәндәр Гыйниятуллин сөйләде. Быел Казан буенча 8 мең хуҗасыз хайванны тотканнар. 296 эт приютта калган, 1017сен төрле җирләргә урнаштырганнар. Хуҗасы булып та, үз көйләренә генә йөргән этләр мәсьәләсе дә ачык кала, дип белдерде урынбасар. Былтыр да, быел да андыйларның кешегә, иң куркынычы – балаларга ташлану очраклары бер генә булмады.

Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт мәсьәләләрен җайга сала торган закон нормалары камил түгел. Утырыштан соң парламент вәкилләре шундый нәтиҗәгә килде. Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, бу җитди сорау белән кабат Дәүләт Думасына мөрәҗәгать итәчәкләр.

Дәүләт Советы сәркатибе Лилия Маврина хәбәр иткәнчә, киләсе утырышта (16 мартта узачак. – **Ред.**) депутатлар 21 сорауга тукталачак, шулар арасында 8 республика һәм 7 федераль закон проекты булачак. Кайбер министрлык, вәкаләтле вәкиллекләрнең былтыргы эшчәнлеге турында хисаплары тыңланачак. Шулай ук Татарстанның өч җәмәгать судьясын сайлау өчен кандидатураларны карау ниятләнә.

Тапшырылмаган басмалар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Сусау

Питрәч районының Көек авылында яшәүче Гүзәлия Миннәхмәтова бу елга «Ватаным Татарстан» газетасына язылган. Тик аңа 1,5 ай буена бер генә сан да килмәгән.

– Без дә татар газетасын укымагач, кем укыр? Бик теләп язылган идем дә бит. Ай буе почта әрҗәсен карап тордым. Юк та юк. Әллә адресны бутаганнармы? Алай дисәң, игъланнарны, коммуналь түләү кәгазьләрен китерәләр бит. Хәзер өмет сүнде, килмәс инде ул, – ди Гүзәлия, аптырап.

Питрәч районының почта бүлегенә шалтыратып, проблеманың сәбәбен ачыкладык. Баксаң, Көектә хат ташучы да, почта бүлекчәсе дә юк икән. Әлеге зур бистә халкы газета-журналларга язылмый дигән сүз.

– Хат ташучы юк. Моңа кадәр берәү «Телесемь» газетасын алдыра иде, илтер мөмкинлегебез булмагач, акчасын кире кайтардык. Газеталарны пенсия тараткан вакытта гына китерсәк инде… Безнең хезмәткәрләр җыелган газеталарны иясенә китерер, – диде почта бүлекчәсе җитәкчесе Юлия Поликарпова.

Сүзләрендә торганнар, иске газеталарны җыеп китергәннәр анысы Гүзәлия Миннәхмәтовага. Тик авыл халкы гел шулай кул селтәп яши алмас бит.

– Көек авылында яшәүчеләргә Богородское почта бүлекчәсе хезмәт күрсәтә. Кызганыч, хәзер бу бүлектә почтальон юк. Әлегә почтаны хатларны аралау участогы җитәкчесе атнага бер тапкыр илтә. Шул ук вакытта клиентлар барлык социаль түләүләрне вакытында ала. Китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәбез, почтальонны тиз арада табарга тырышырбыз. «Ватаным Татарстан» басмасын китерүне контрольгә алдык. Көектә почта бүлекчәсе ачу өчен таләпләргә туры килә торган бина эзлибез. Шуны тапкач, ача алачакбыз, – диделәр «Татарстан почтасы» идарәсендә.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Рамил ТӨХВӘТУЛЛИН, Татарстан Дәүләт Советы депутаты:
– Әлбәттә, хат ташучылар проблемасын хәл итеп була. Беренче чиратта, эш хакларын күтәрергә кирәк. Күп өлкәләрдә кадрлар кытлыгы күзәтелә, чөнки эш хакы аз. Хезмәт хакы яхшы булса, кеше үзе теләп барачак. Бөтен нәрсә матди якка бәйле. Газеталар ияләренә барып җитми, аны яздырту мөмкинлеге юк икән, әлбәттә, рухи байлыктан мәхрүм булабыз. Кайвакыт түләү квитанцияләрен дә илтмиләр, аннан штраф пенясы алалар. Алар үз чиратында, без юллыйбыз, диләр. Хат ташучылар җитмәү сәбәпле, барып җитмидер. Аннан, пеня түләмәдегез, дигән сылтау табалар. Бу – башбаштаклык дигән сүз. Өлкәннәр газетаны кулга тотып укырга ярата, мин дә шулай. Интернеттан уку ләззәт бирми. Әби-бабайларга почтага бару кыен. Кыш көне егылып имгәнүләре бар. Почтага керсәң, чират. Чәй, токмач сату – башка кәсеп. Алардан сатучылар ясау башка сыймый. Проблеманы бер-ике көндә дә хәл итәргә мөмкин. Аның белән бары шөгыльләнергә генә кирәк. Тик моны республика гына чишә алмый дип уйлыйм. Бу – ил сәясәте. Теләк тә юк, шөгыльләнергә исәпләре дә юк. Безгә почта проблемалары буенча мөрәҗәгать итүчеләр юк. Булса, төбенә төшеп өйрәнер идек. Әгәр мондый мөрәҗәгатьләр булса, безгә хәбәр итсеннәр.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА, «Ватаным Татарстан» газетасының подписка һәм реклама буенча баш мөхәррир урынбасары:
– Редакциягә, газетага язылган идек, килми, дип еш шалтыраталар. Әлбәттә, без бер генә мөрәҗәгатьне дә җавапсыз калдырмыйбыз. Нигә вакытында китермәүнең сәбәбен ачыклыйбыз, мәсьәләне уңай хәл итәргә тырышабыз. Шунысын да аңларга кирәк: һәрбер редакция көнен, сәгатен авыштырмыйча, газетаны график белән чыгара, ә менә газетаның укучысына барып җитүен тәэмин итү бездән тормый шул. Монысы инде турыдан-туры почта хезмәтенә бәйле. Газетага язылу бәясенең дә күп өлеше нәкъ менә газетаны тарату өчен китә. Әлеге очракта халыкны да бераз таләпчәнрәк булырга чакырыр идем. Югыйсә акча түләнгән, нигә газета китермиләр? Тегүчегә күлмәк тегәргә биреп, ул хезмәтен башкармаса, хокукларыбызны яклар идек бит. Газетаны китермәсәләр дә, шул ук хокукларыбызны бозу дигән сүз. Почта безгә килми, газеталарга язылмыйбыз, дип тә бу проблемадан качарга кирәкми. Ә бәлки һәр җирлектә почта хезмәтенең тиешенчә оештырылуын ныграк таләп итәргәдер. Күп кенә авылларда почта бүлекләре ябылып бара. Бу – авылларның бетүенә дә тагын бер адым. Сүз дә юк, әлеге проблема Россия күләмендә хәл ителергә тиеш. Ничек кенә булса да, проблеманы яшерергә, аннан качарга кирәкми, бу сорауны ешрак күтәрик. Хат ташучыларның тиешле хезмәт хакы алуына, газета-журналларның вакытында укучыларыбызга барып җитүенә ирешү – иң зур хыялыбыз.

ХУШЛАШЫРГА ИРТӘРӘК



pixabay.com

COVID-19

Соңгы арада коронавирус турында сөйләшүләр сирәгәйсә дә, чирнең кеше арасында булуын онытырга ярамый. Әйтик, узган тәүлектә инфекция йоктырган 638 кеше теркәлгән. Авыручылар санының ел башыннан бирле күзәтелгән үсеше хәзер юк дип ышандыралар. Узган атна белән чагыштырганда, андыйлар 41 процентка кимегән.

Чирләүчеләрнең кимүе республикада гамәлдә булган чикләүләрне бөтенләй юк итү өчен нигез түгел. Сүз бигрәк тә кафе-ресторан, клубларның төнге эшчәнлегенә бәйле. Бу тармак вәкилләре чикләүләрне бетерү турында бер генә мөрәҗәгать итмәде инде.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, бу сорауга март азагында җавап булырга тиеш.

– Клуб, кафе-ресторааннарның төнге эшчәнлеген чикләү – федераль норма. Ул Россиянең баш санитар табибы карарында да язылган, – дип аңлатты белгеч. – Ресторааторлардан килгән мөрәҗәгатьләр бер ай карала. Март азагына бу сорауга кире кайтачакбыз. Бәлки, федераль нормага да үзгәрешләр керер.

Чирләүчеләр саны кими дисәләр дә, вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпитальләрендә коронавирусны авыр формада кичерүчеләр бетмәгән әле. Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков сүзләренчә, реанимациядә дәваланучы сырхаулар һаман бар. Кабул итү бүлекләренә халыкның азрак килүе медицина оешмалары эчендә эш тынганы турында сөйләми, ди белгеч. Кыскасы, табибларга иркен суларга мөмкинлек юк әле.

САН

◆Республикада халыкның 81,24 процентан артыгы вакцина ясаткан. 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында 640388 кеше вакцинациянең беренче этабын узган. Ревакцинация узган кешеләр саны – 258551. Шулай ук республикада балалар һәм яшүсмерләргә вакцина ясау дәвам итә.

◆18 яшькә кадәрге 2006 бала прививка кадаткан.

Авыл капкасы

ТАРТУ КӨЧЕ

Кайдадыр яшь белгечләргә кытлык зур булса, Балтач районының «Татарстан» хуҗалыгы соңгы елларда андыйларга шактый баеган. Бүген биредә 35 яшькә кадәрле 17 югары белемле белгеч эшли. Кайткан берсен кире бормыйлар, эш тә, урын да табалар.

– Күбесе үзебезнекеләр, яшьтән шушы хуҗалыкта хезмәт куеп, үзләрен күрсәтеп киткән егетләр, – ди хуҗалык җитәкчесе Айнур Нотфуллин. – Соңгы елларда югары белем алып кайткан егет-кызларыбызның бөтенесен диярлек «целевой» белән укыттык. Бүген дә өч егетебез ветеринария академиясендә белем ала. Тиешле стипендиясен түләп барабыз, кайткан һәркайсына белеме буенча эш бирергә тырышабыз. Хәзер югары белемле белгечләрдән башка булмый. Технология заманы, гел зураябыз, киңәябез… Эшкә кайтучыларга хөкүмәт программасына керергә булышабыз. Үткән ел ике фатирлы йорт төзедек, ул да торакка мохтаҗ белгечләргә дип тәгаенләнде.

Тагын шунысы бар: хуҗалыкка кайткан югары белемле егет-кызларның барысы да – заманында данлыклы булган әби-бабайларының, бүген хезмәт куючы әти-әниләренең эшләрен дәвам итүчеләр. Читтән килеп эшләүче белгечләр дә чит түгел биредә.

Баш икътисадчы Шамил Гомәров Казандагы акчалы, киләчәге булган эшен калдырып кайткан.

– Казанда эшләсәм дә, авылдан аерылмадым диярлек, – ди Шамил, кайтуының сәбәпләрен сорашкач. – Атна саен кайтып йөрдек. Элекке сыйныфташым – хуҗалык җитәкчесе Айнур Нотфуллин чакыргач та әллә ни озак уйланмадым. Күрәсең, күңелдә инде мондый фикер туган булгандыр. Ни дисәң дә, авылда әти-әнинең дә яше бара. Ә тормыш-эш шартларына килгәндә, кайда да эшлисе, тырышасы. Авылда да тырышып эшләгән кеше начар яшәми. Хәзер инде шәһәр-авыл арасында яшәү шартлары буенча әллә ни аерма юк. Мөмкинлекләр, уңайлыклар бер үк. Дөрес, монда кайтуымны аңламаган кешеләр дә булды. Кем шәһәрдәге шундый эшен калдырып авылга кайта инде диючеләр дә табылды. Әмма мин үкенмим. Монда кайтып эшли башлагач, Гөлназ белән гаилә кордык, улыбыз үсә. Икебез дә шушы авылдан без.

Гөлназ «целевой» буенча авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлаган. Үсемлекчелек буенча хисапчы. Ул да авылга кайтканына үкенми. «Уйлаган кешегә Казан монда гына бит, ике сәгатьлек юл», – ди ул…

Үткән ел Гомәровлар өчен бик тә сөенечле була: үзләренең яңа йортларына күченәләр. Яшьләрдән торган яңа урамда, дәүләт программасы нигезендә салынган йортлары икесенең дә төп нигезеннән ерак түгел. Димәк, әти-әниләренә ярдәм итеп яшәргә дә бик уңайлы.

Шушы көннәрдә генә хуҗалыкның тагын ике белгече – баш агроном Фирдүс Хәкимов белән үткән ел гына авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлап кайткан Илзирә Галләмова гаилә корган. Яшь белгечләр кайту, гаилә корулары икеләтә куанычлы: авылда төпләнеп калган менә шундый гаиләләр авылларның өмете, киләчәге бит инде.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Гөлназ белән Шамил

ЯГЪФӘР ШӘМИЕВ:

«ФИЗИК ТӘРБИЯ ҖИТЕШМИ»

Язгы кояш нурларын сирпеп, кар эри башлаганда, Ягъфәр Шәмиевнең үзенчә борчыла торган гадәте бар. Шатланырга гына кирәк бит инде югыйсә: көннәр җылына, җир яшәрә дигәндәй… Юк, аңа чаңгы шуарга кирәк. Тугызынчы дистәне вакладым дип тә тормый, көн саен Казансу буйларыннан дистәләрчә чакрым юлны әйләнеп кайту аңа берни түгел. Арчада ветераннар арасында үткәрелгән ярышларда катнашмый калганы юк, республиканыкына да өлгерә. Һәрберсендә диярлек призлы урыннар яулый.

Ягъфәр Шәмиевнең шәхси архивыннан

Спортчылар бар ул

Ягъфәр Зыятдинович: «Спортчылар бар ул, физик тәрбия бирүчеләр генә җитешми», – дип әйтергә ярата. Үзе 50 елдан артык гомерен шушы һөнәргә багышлаган. Арчада беренчеләрдән булып, «Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре» дигән исемгә лаек булган. Әлбәттә инде, аның хезмәте һич кенә дә педагогия көллияте диварларына гына сыймаган. Ни өчен дисезме? Беренчедән, бу уку йортында мускулларын ныгыткан, зур уңышларга ирешкән спортчылар башта – көллият, аннан Арча районы, республика, ахыр чиктә ил данын яклый. Икенчедән, аның күпме укытучы тәрбияләп чыгаруын санап бетерерлек тә түгел. Аларның күбесе республикабыз авыл-районнарында остазлары эшен дәвам итә, яңадан-яңа спортчылар тәрбияли. Арчаның елдан-ел шәбрәк күрсәткечләргә ирешүче спорт комплексларында да аның шәкертләре эшли. Шуңа күрә ул бүген дә үзен бик җаваплы хис итә. Бу аңлашыла да. Институтны тәмамлаганнан соң әзергә килмәгән бит, тиз арада Россия ярышларында призлы урыннар алырлык дәрәҗәгә ирешелгән, шушы төбәк өчен күпме көч, хезмәт куелган.

– Мин педучилищега эшкә килгәндә, форма дигән нәрсә гомумән юк иде. Физкультура дәресләренә кем киез итектән, кем бишмәттән йөри. Спорт инвентарьлары турында әйткән дә юк. Бернинди секцияләр оештырылмаган иде, – дип искә ала ул укыта башлаган вакытларын. – Эшне яңабаштан корырга, физкультура укытучылары арасында спорт төрләрен үзара бүлешергә кирәк иде. Шулвакыт хезмәттәшләрем миңа чаңгы секциясен ышанып тапшырдылар.

Чаңгычылар озак көттермиләр. Беренче елларда ук район, республика ярышларында алдынгы урыннарга чыгалар, Россия Мәгариф министрлыгы үткәргән ярышларда да катнашу бәхетенә ирешәләр.

Шәкертләре белән, чыннан да, эшли беде Ягъфәр Зыятдинович. Кемнең нәрсәгә сәләтле икәнен бер карауда сизә кебек иде ул. Үземнең дә чаңгы шуып йөрергә әллә ни теләгем юк иде. Башта сүз тыңлап йөргән кебек кенә булдым, аннан ничек итеп «кармак»ка эләккәнемне сизми дә калдым. Эшләтә дә, күңелне дә күтәрә, кирәк чакта юата да белә иде ул. Сигез дәрес укыганнан соң Казансу буена күнекмәләр ясарга шатланып, горурланып төшеп китә идек. Югыйсә дәрес тә әзерлисе, музыкага да өйрәнәсе, ашау-эчүне дә кайгыртасы бар бит әле. Яшәү шартлары да әллә ни түгел иде. Ягъфәр Зыятдиновичның иртә белән тулай торакка килеп, үз спортчыларын зарядкага алып чыгып китүе – үзе бер тарих. Спорт белән шөгыльләнмәгәннәрне дә аякка бастырып китә иде ул. Әле хәзер дә очрашкан чакларда шул мизгелләр хакында сөйләшәбез. Күбесе, йокларга да ирек бирмәде инде, дип зарланган була, әмма күренеп тора: барыбер сагынып, яратып искә алалар.

Үҗәт малай

Үҗәтлек – теләсә нинди авырлыктан чыгарга ярдәм итүче сыйфаттыр ул. Әтиләре сугышка киткәндә, әниләре кулында җиде бала кала алар. Сукыр бабалары да бар. Ягъфәргә ул вакытта – 3 яшь. Шөкер, әтиләре исән-сау әйләнеп кайта. Ачлык-ялангачлыктан тиз генә котылып булмаса да, тормыш җиңеләйгән сыман була. Шулай да 7 яшьтә укырга бара алмый әле ул: өстенә кияргә киеме булмый. Аптырап калмый: абыйларыннан калган иске бишмәтнең җиңнәрен кисә дә сырган чалбар тегә. Тик менә тау шуарга ни чаңгысы, ни чанасы юк бит әле. Малай мунчада койма тактасыннан төннәр буе чаңгы ясый. Әтисе моны күреп ала да, тезенә куеп, сындырып кына ата, янәсе, чаңгы шуып, итекләрне эштән чыгара. Ягъфәр тагын ясый, бу юлы инде, әтисе күрмәсен дип, шуып кайтканнан соң яшереп куя башлый. Армиягә киткән абыйсының гармунында уйнарга өйрәнергә дә мунча ярдәм итә. Төннәр буе «эшләп» чыккач, мәктәптә утырган җирдән йоклап киткән чаклары да булгалый. Укытучылардан да эләгә. Урамда күп йөрисең дип, әти-әнисе дә әрли. Әмма Ягъфәр чаңгы шуудан туя алмый. Биек тауга менә дә бөркет кебек түбәнгә томырыла. Мондый мизгелләрне бернигә дә алыштыра алмый ул. Күрәсең, малайда ихтыяр көче, тизлек, биеклеккә ашкыну кебек хисләр әнә шулай тәрбияләнгәндер.

Йөрәк әрни

– Бүгенге мөмкинлекләр ис китәрлек, әмма физкультура белән шөгыльләнүчеләр генә бармак белән санарлык. Вакыт юк дигән булалар. Шуңа йөрәк әрни, – ди остаз. Сәламәтлек турында сүз барганда, ул вакыт юклыкка сылтауны ишетергә дә теләми. Чыннан да, ул үзе балачактан озата килгән һөнәрләрен бер дә онытмаган. Тегә, аяк киемнәре төзәтә, бар кешене сокландырып, тальянын сузып җибәрә. Җәйләрен яр буенда балык чирттерергә ярата. Балалары, оныклары белән аралашырга да өлгерә.

– Хәзер бигрәк тә өлкән яшьтәгеләр өйдә, диванда сузылып ятарга яраталар. Бала-чага сыман компьютерда, телефонда уйнап утырырга да күп сорамыйлар. Саф һавага чыкмыйлар диярлек. Режим белән ашамыйлар, аз хәрәкәтләнәләр, – дип борчыла ул.

Без остазым белән элеккеге чакларны искә төшерергә яратабыз. Бервакыт шулай Ягъфәр Зыятдинович иртә белән дә, кич белән дә Кенәр юлына таба чыгып, йөгереп кайтуны гадәткә керткән иде. Башта шәкертләрен алып китте, аннан укытучылар кушылды, соңга таба Арча халкы да чыга башлады. Үзенә бер күңелле бәйрәм кебек иде ул. Танышып, очрашып кайтырга да форсат чыга иде. Физик тәрбия дигәннәре менә шундый гап-гади гамәлләрдән башланадыр, бәлки.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары **Камалтынов** Юрий Зимелевич, республиканың массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Эфир» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Директорлар советы рәисе **Григорьев** Андрей Парамонович, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен хезмәт ветераны **Никонова** Валентина Геннадьевна, күпьеллык намуслы хезмәте һәм республиканың юл-транспорт төзелеше тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татавтодор» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Шәймиев** Айрат Минтимер улы, Пекин шәһәрендә (Кытай Халык Республикасы) 2022 елгы XXIV Кышкы олимпия уеннарында югары спорт күрсәткечләренә ирешкәне өчен «Россия җыелма спорт командаларын әзерләү үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең тимераякта фигуралы шуу буенча Россия Федерациясе җыелма спорт командасы спортчы-инструкторы, «Татарстан Республикасының тимераякта фигуралы шуу федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы спортчысы **Тарасова** Евгения Максимовна **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен хезмәт ветераны **Галиуллин** Мидехәт Гарифулла улы, Пекин шәһәрендә (Кытай Халык Республикасы) 2022 елгы XXIV Кышкы олимпия уеннарында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасының трамплиннан чаңгыда сикерү һәм ике төрдәге чаңгы ярышлары федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты **Вәлиев** Әнәс Кавый улы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры **Смолкин** Михаил Владимирович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Заһитов** Әксән Заһит улы, «АК БАРС» акционерлык коммерциячел банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) Акча әйләнеше һәм кыйммәтле әйберләрне транспортта йөртү департаменты директоры **Абдрахманов** Эдуард Мансур улы, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары **Габдрахманов** Илдус Харис улы, «Россия сегодня» халыкара мәгълүмат агентлыгы» федераль дәүләт унитар предприятиесенең Мәгълүмат буенча баш дирекциясе Гомумроссия мәгълүмат идарәсенең төбәк мәгълүмат редакциясе (Казан шәһәре) үзхәбәрчесе **Дурницына** Ирина Николаевна, «Российская газета» редакциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Казан шәһәрендәге филиалы өлкән хәбәрчесе **Кондрева** Ольга Ивановна, «Беренче канал» акционерлык җәмгыятенең Мәгълүмати программалар дирекциясе Эфир хезмәте Россия һәм чит ил хәбәрләре җиткерү челтәре бүлеге Идел буе бюросы (Казан шәһәре) хәбәрчеләр пункты мөдире **Костина** Светлана Валерьевна, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыятенең мәгълүмати һәм иҗтимагый-сәяси программалар дирекциясе баш мөхәррире **Хәбибуллина** Сәрия Нуретдин кызы; Пекин шәһәрендә (Кытай Халык Республикасы) 2022 елгы XXIV Кышкы олимпия уеннарында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасының тимераякта фигуралы шуу федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы тренеры **Траньков** Максим Леонидович, Россиянең атказанган тренеры **Тутберидзе** Этери Георгиевна, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Трамплиннан чаңгыда сикерү һәм ике төрдәге чаңгы ярышлары буенча А.В. Звягинцев исемендәге олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Федорук** Андрей Николаевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Пекин шәһәрендә (Кытай Халык Республикасы) 2022 елгы XXIV Кышкы олимпия уеннарында югары спорт күрсәткечләренә ирешкәннәре өчен «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерциячел предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак барс» хоккей командасы спорт блогы спортчы-хоккейчысы **Билалов** Тимур Рафаил улы, «Россия җыелма командаларының спорт әзерлеге үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең сноуборд буенча Россия Федерациясе җыелма спорт командасы спортчы-инструкторы, «Россия сноуборд федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе спортчысы **Вайлд** Виктор Айван, «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерциячел предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак барс» хоккей командасы спорт блогы спортчы-хоккейчысы **Воронков** Дмитрий Сергеевич, «Россия җыелма командаларының спорт әзерлеге үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең тимераякта фигуралы шуу буенча Россия Федерациясе җыелма спорт командасы спортчы-инструкторы, Мәскәү шәһәренең Спорт департаменты «Самбо-70» спорт һәм мәгариф үзәге» Мәскәү шәһәре дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе спортчысы **Морозов** Владимир Евгеньевич, «Россия җыелма командаларының спорт әзерлеге үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең чаңгыда трамплиннан сикерү буенча Россия Федерациясе җыелма спорт командасы спортчы-инструкторы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе спортчы-инструкторы **Садриев** Данил Марсель улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

Язылганга кайтып

ЯЗМЫШЛАРНЫ СЫНДЫРГАН ФАҖИГА

Казанда яшәүче Галимуллиннар гаиләсе турында моннан ун ел элек язып чыккан идек. Ул чакта Ралиф абый белән Роза апаның уллары Ленарга ярдәм кирәк булды. Тиздән өйләнергә җыенучы егет, эштән кайтканда машинасы белән фаҗигагә очрап, гомерлеккә гарип калды. Әле ул чакта әнисе дә, туганнары да Ленарның аякка басасына ышана иде. «ВТ» газетасы 2018 елда әлеге гаиләгә ярдәм йөзеннән хәйрия концерты да оештырды. Бу гаилә белән даими элемтәдә торабыз. Менә тагын хәлләрен белештек.

– Ирем Ралиф 2011 елда йөрәк өянәгеннән үлеп китте. Улым Ленарны аның урынына эшкә алдылар. Бик яратып эшләп йөри иде. Сөйгән кызы белән гаилә корырга исәпләп тордылар. Тик барысы да без дигәнчә генә түгел шул. Зур сынау алда көткән икән. 2012 елның декабрендә улым фаҗигагә очрады. Машинаның тормозлары эшләмәгән, диделәр, – дип искә ала Роза апа.

Ул чакта Ленарны Санкт-Петербург табиблары да килеп карый. Күңелне сөендерерлек берни әйтмәсәләр дә, сабыр итәргә кушалар.

Роза апа инде 10 ел сабыр итә. Баштарак, оныгын карашырга дип, Балык Бистәсе районында яшәүче әбиләре дә килгән була. 4 елдан соң, Ленарның хәле бераз җайлана төшкәч, ул авылга кайтып киткән.

– Мин 28 елдан артык 16 нчы хастаханәдә шәфкать туташы булып эшләдем. Улыма ярдәм кирәк булгач, эшемне ташларга туры килде. Элегрәк безгә хәйрия фондлары ярдәм итте. Алар ярдәме белән тернәкләндерү үзәкләренә йөрдек. Ленар инде беренче еллардагы кебек түгел. Утыра ала, сызланулары юк. Авырыйм дип зарланмый. Безне танымаса да, янына кеше килгәнне ярата. Берни әйтә алмый. Аның үз дөньясы. Әмма яратканда, чәчләреннән сыйпаганда йөзендә елмаю сизелә, – ди Роза апа.

Ленарны туганнары, дуслары, бергә эшләгән хезмәттәшләре, сыйныфташлары ташламый. Алар Роза апага ярдәм итеп тора. Ә төп ярдәмчеләре – кызы белән Ленарның сөйгәне Диана. Роза апа Диананың әле дә ялгыз булуына борчыла.

– Улымны яратуы көчле булгандыр инде балакаемның. Күпме генә әйтеп карасам да, кияүгә дә чыкмады. Ә бит яше бара… Бер фаҗига ике кешенең язмышын челпәрәмә китерде, – ди Роза апа.

Әлеге гаилә якыннары ярдәме белән яши. Алар биргән акчага атнага ике тапкыр инструктор чакыртып, күнегүләр ясаталар. Кирәк-яракны да шул акчага алалар.

– Безне ташламаган, ярдәм итеп торган һәр кешегә чиксез рәхмәтлемен. Тормыштан зарлана алмыйм. Без күрәсен кеше күрми. Тәкъдиремә, димәк, шулай язылгандыр. Иң мөһиме – авырып кына китмәсен. Ә калганын ничек тә күтәрәбез аның, – ди әнисе.

Ленар Галимуллинга ярдәм итәргә теләүчеләр 89047645341 телефон номерына беркетелгән Саклык банкы картасына акча күчерә ала.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Рәсми документлар

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышын 2022 елның 16 мартында 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 11 марты
№ 1358-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрының полиция эшчәнлеге турында 2021 елгы хисабы.
3. «2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.
4. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2021 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы.
5. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап.
6. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 272-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 274-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләр турында» 266-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 275-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 268-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Һөнәр берлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 276-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 277-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 273-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
15. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 61739-8 номерлы федераль закон проекты хакында (социаль-икътисадый үсеше алга киткән территорияләрнең исемен үсеше алга киткән территорияләргә алмаштыруга бәйле рәвештә).
16. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 11^1 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 74544-8 номерлы федераль закон проекты хакында (диңгездәге файдалы казылмаларның яңа чыганакларына салым салуны камилләштерү турында).
17. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 251 һәм 262 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 71616-8 номерлы федераль закон проекты турында (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә мөлкәт хокукы рәвешендәге керемнәргә карата оешмалар табышына салым буенча ташламаларның гамәлдә булуын яңарту өлешендә).
18. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законның 2 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 68371-8 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының яисә аларга ведомство буйсынуындагы органнарның рәсми битләрен булдыру өлешендә).
19. «Концессия килешүләре турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 75205-8 номерлы федераль закон проекты хакында (концессия килешүе, дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр төзү өлешендә).
20. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм урта һәм кече эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне аерып алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 1065429-7 номерлы федераль закон проекты хакында (күчемле мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен урнаштыру өлешендә).
21. «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында (күпфатирлы йортта энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары өлешендә)» 1077816-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 11 марты
№ 1359-VI ДС

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

ТҮГӘРӘК ДӨНЬЯСЫ

Безнең Җир шары шундый кызыклы. Аның серләрен кайсыгыз белә икән?

1. Лондонда сәгать кичке 9 булганда, Төньяк полюста ничә?
А) иртәнге 8;
Б) иртәнге 6;
В) кичке 9.

2. Дөньяда нинди диңгез юк?
А) зәңгәр;
Б) кара;
В) сары.

3. Цейлон утравының икенче исеме.
А) Калининград;
Б) Мадагаскар;
В) Шри-Ланка.

4. Антарктидадагы диңгез.
А) Әдрән;
Б) Уэдделла;
В) Амазон.

5. Россия территориясендә булмаган елга.
А) Идел;
Б) Днестр;
В) Рейн.

Җаваплар: 1) В; 2) А; 3) В; 4) Б; 5) Б.

Ата-ана колагына

Өстенлек – җиләк-җимешкә

Язын витамин җитмәү балага да кагыла. Иммунитет какшаса, вируслы авыруларның кунак булып килүен көт тә тор. Яшь организмга язын нәрсә кирәк? Әти-әниләргә түбәндәге киңәшләрне истә тоту зыян итмәс.

1 Төп кагыйдә – төрлелек. Бала рационында ипи дә, ярма да, яшелчә дә, җиләк-җимеш тә, ит, балык, йомырка, майлар, сөт ризыклары да булырга тиеш. Ара-тирә тәм-том да. Ботка, ипи, макарон – бала өчен көч һәм энергия чыганагы.

2 Бала көненә бер тапкыр җиләк-җимеш ашаса яхшы. Әйтик, алма, әфлисун, анар җимеше, банан.

3 Кәнфит, тортларны өйдә ясалган кайнатмалар, җиләк-җимеш пюрелары белән алмаштыру яхшырак. Газлы, баллы сулар урынына исә – компот, бал белән чәй.

4 Бала организмына үгез, куян, күркә, тавык ите файдалы. Ит гемоглобинны тиешле дәрәҗәдә тотарга ярдәм итә.

5 Сарымсак, суган турында да онытмагыз. Алар – авырулар алып килә торган микроблар белән көрәштә төп ярдәмче.

АЗАМАТ ЗӘЙНУЛИН:

«Журналистлар тик тормый – шунысы ошый»

Бүген бездә кунакта – булачак журналист яисә режиссер Азамат ЗӘЙНУЛИН. Үзе катнашкан күпсанлы проектларга ничек килеп эләккән ул? Яшьтәшләренә ниләр киңәш итә? Барысын да үзе сөйләр.

:: Азамат, сине без яшь журналист буларак беләбез. Бу өлкәдә кайчаннан бирле «кайныйсың» инде?
– Мин кечкенәдән «Нур» театр студиясенә йөрдем. Шунда беркөнне Нурания апа Җамали килде. Яңа ел төнендә күрсәтеләчәк сериалда катнашыр өчен кастинг уздырды ул. Нәтиҗәдә мине һәм туганымны сайлап алдылар. Шул сериалда катнашканнан соң, мине «Яшь ТНВ»га дәштеләр. Бик теләп ризалашып, эшли дә башладым. Аннан соң «Шаян ТВ» телеканалы ачылды, анда да кастингта катнаштым. Әлегәчә шунда эшлим.

:: Нинди тапшырулар алып барасың әле?
– «Шаян тарих» һәм «Шаян балалар»ны.

:: Аларны үзегез әзерлисезме?
– «Шаян тарих» тапшыруы мисалында сөйләп китәм. Коллегам Зилә Хәбибуллина белән без төрле тарихи урыннарга барып, алар турында сөйлибез. Башта тапшыру төшереләчәк урынны сайлап, редактор белән килештерәбез. Аннан текст язабыз, тагын килештерәбез. Һәм инде төшерәбез. Әле күптән түгел редактордан башка гына эшли башладык. Барысы өчен дә үзебез җаваплы.

:: Тапшырулар әзерләүнең кайсы ягы ныграк ошый?
– Тапшыруның текстын үзебез язабыз, дип әйттем инде. Язган чакта, моңарчы ишетмәгән фактлар белән танышабыз, үзебез өчен яңалыклар ачабыз. Менә шул ягы ошый миңа. Гомумән, журналистлар бер тик тормый бит ул, гел хәрәкәттә, димәк, үсештә. Шуңа да якындыр миңа бу өлкә.

:: «Шаян ТВ»ны үзең карыйсыңмы? Безнең укучыларга нинди тапшыруларны киңәш итәр идең?
– Әлбәттә, карыйм. Мактану дип кабул итә күрмәгез, безнең барлык тапшырулар да шәп, әмма мин үзем алып бара торганнарын киңәш итәм.

:: Син безгә «Бер-бер хәл» сериалы аша да таныш. Аның турында да сөйлә әле.
– О, бик кызык булды ул. Мине ике этаплы кастингка чакырдылар. Беренчесе студиядә узды. Камера алдында үземне тота аламмы, рольгә керү кыен түгелме, шуларны тикшерделәр. Икенчесе исә сериалны төшерү мәйданчыгында узды. Һәм… мине сайлап алдылар.

Съемкалар өч айга сузылды – җәй буе төшердек. Янымда тәҗрибәле актерларның ярдәмнәрен тою үзе бер рәхәт иде. Гомумән, төшерү группасы белән бер гаиләгә әйләнеп беттек диярлек.

:: Сериалдагы ситуацияләр – балалар белән әти-әниләрнең русча аралашуы, компьютердан аерыла алмау – бу хәлләр танышмы сиңа?
– Юк. Без өйдә бары татарча гына аралашабыз. Әти-әни белән дә, туганым, дәү әти һәм дәү әни белән дә. Татар гимназиясендә белем алгач, дусларым янында да тел алыштырырга туры килми.

Кунагыбыз турында белешмә

- Азамат Казанның Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә 10 нчы сыйныфта белем ала.
- Аның Салават исемле игезәк туганы бар.
- Киләчәктә йә журналистика, йә режиссура бүлегендә белем алырга тели.
- Бераз гына гитарада уйный.

:: Яраткан китабың һәм фильмың нинди?
– Китаплардан – Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» әсәре, ә фильмнардан – «Мальчик в полосатой пижаме» (реж. – Марк Херман. – **Ред.**).

:: Азамат, синең кебек булырга теләгән яшьтәшләреңә нинди киңәш бирер идең?
– Иң мөһиме – курыкмаска һәм үз-үзеңә ышанырга. Мөмкинлекләр күп, фестиваль-бәйгеләрдә катнашып, үзеңне сынарга була. Әйтик, җәй саен яшь журналистлар «Алтын каләм»гә җыела. Мин бик күп дусларым белән шунда таныштым. Гел алга омтылырга һәм тырышырга гына кирәк.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТЕЛЕВИЗОР КАРАУ КАГЫЙДӘСЕ

! Телевизорны озак карау баланың сәламәтлегенә – нерв системасы, күзләр, буй-сынга начар тәэсир итә. Телевизор тирәсендәге электромагнит кыры, гомумән, бөтен организм өчен зыянлы.

! Телевизор торган бүлмәдә тиешле дәрәҗәдә яктылык булырга тиеш. Артык караңгы һәм артык якты бүлмәдә утыру шулай ук зыянлы.

Онытма!

Телевизорны ян белән, кырыйдан карау ярамый.

Телевизор экраны һәм бала арасы 3 метр булырга тиеш.

Озак бара торган тапшыру, фильм караган очракта, күзләргә гимнастика ясап алу зарур.



Телевизор караганда ашарга ярамый. Бу – бердән, начар гадәт, икенчедән, симерүгә яисә сәламәтлеккә бәйле башка проблемаларга китерә.

Телевизор карау ике яшькә кадәр балаларга, нерв системасы бозылган, нерв-психик үсешендә тайпылышы булган, артык тәэсирләнүчән балаларга тыелган. Күз күрү белән бәйле проблемалары булганнарга да телевизор каршында көн үткәрү хәерлегә түгел. 3–7 яшьлек балаларга телевизорны көненә 30 минут кына карарга рөхсәт ителә.



Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

Бәхәс

Тәнәфескә чакырып кыңгырау шалтырауга, Әфләтүнев, олы йодрыкларын чалбар кесәсенә батырып, ашыкмый гына коридорга чыкты. «10 сыйныф» дип язылган, бер генә күгәндә асылынып торган калтырча ишекне аягы белән тибеп ябып, менә торган баскычка таба атлады.

Нәрсә соң ул «менә торган» баскыч, дисезме? Әфләтүнев укый торган мәктәп ике катлы һәм аның ике башында ике катны тоташтыручы ике баскыч бар. Тәнәфестә ашханәгә йөгерүче укучылар бер төркем икенче төркемгә бәрелеп, авария килеп чыкмасын өчен, мәктәп директоры махсус карар кабул иткән: баскычларның берсеннән фәкать менәргә, икенчесеннән фәкать төшәргә! Әлеге карарны үтәмәүчеләр «Тәртипсезләр дәфтәре»нә языла һәм һәр дүшәмбедә була торган линейкада аларның фамилияләре бөтен укучылар алдында кычкырып әйтелә.

Шулай итеп, Әфләтүнев, өстән аска юл тотуына карамастан, менә торган баскычка атлады.

– Моннан төшәргә ярамый! – дип каршына чыккан дежур малайны колагыннан тотып кына читкә алып куйды һәм аска төшеп китте. Юлында очраган бәләкәй малайлар стенага елышып аңа юл бирде – ул аларның кайсына аяк чалды, кайсының башына «шалбан» биреп китте.

Әфләтүневнең кем икәнен чамалый башладыгызмы инде? Чамаласагыз, аның ничек итеп җыештыручы Маһинур әбигә сүгенүен, «Безнең отличниклар» дигән стендка ботинкасын ышкып китүен, яшь укытучы Гөлиягә «ялгыш кына» аяк чалуын тәфсилләп язып тормыйбыз. Кыскасы, тагын ике минуттан ул, бишенче сыйныфлар янына кереп, аксыл чырайлы, сипкелле малай янында басып тора иде инде:

– Дөрес булса, сине бәхәстә һәрвакыт җиңә диләр. – Әфләтүневнең иреннәре, алда булачак кызыкны тоеп, мыскыллы елмая, күзләре төссез һәм нурсыз иде. – Бәхәсләшәбезме?

Берничә секунд тынлыктан соң сипкелле малайның зәгыйфь тавышы ишетелде:

– Бәхәсләшик… Нәрсә дип бәхәсләшәбез соң?

Әфләтүневнең мыскыллы елмаюы көчәя төште:

– Сине гений диләр бит! Уйлап тап бирәр нәрсә!

Сипкелле малай чак кына уйланып торды:

– Ярый. Алайса… Алайса, менә болай. Әйтик, мин синең маңгаеңа ун тапкыр чиертәм һәм син миңа… моның өчен рәхмәт әйтәчәксең!

Әфләтүнев шаркылдап көлеп җибәрде:

– Шә-ә-п!.. Шәп әйттең! Мин сиңа рәхмәт әйтәчәкмен! Ха-ха-ха… Супер! Шәп! Гениально! Ну, нәрсәдән бәхәсләшәбез? Илле сумнан! Килештекме?!

– Килештек! – диде сипкелле малай, бәләкәй кулын сузып. – Түлке иртәгә чиертәм, ярыймы? Бүген бармагым авыртыбрак тора…

Малайлар учны учка шапылдатты.

Иртәгесе көн озак көттермәде. Сөйләшенгән вакытта мәктәп ишегалдының аулак почмагында Әфләтүнев сипкелле малайны көтеп тора иде инде.

– Йә?! – диде ул, иренен чалшайтып.

Сипкелле малай ашыкмый гына кулларын төкреклә-де, җиңнәрен сызганды һәм аяк очларына үрелеп, тәмләп кенә Әфләтүневнең маңгаена чиертә башлады:

– Бер! Ике! Өч!.. Ун!

Әфләтүнев кызарган маңгаен ышкып алды:

– Ну! – диде ул усал гына. – Әйттемме рәхмәт дип? Ә?! Чыгар акчаңны, көчек! Юкса…

Сипкелле малай авыр сулап куйды һәм кесәсеннән өр-яңа иллелек тартып чыгарды:

– Син җиңдең… – диде ул тонык тавыш белән.

Әфләтүнев йодрыкларын уйнатып алды:

– Шулай, көчек, моннан соң бәхәстә һәркемне җиңәм дип әтәчләнеп йөрмә, яме! Булдыра алганыңны гына эшлә! – Ул кондәшеннән акчаны йолкып диярлек алды һәм йодрыкларын кесәсенә батырып, эре-эре адымнар белән китеп бар… юк, китәргә өлгермәде, сипкелле малайның карлыккан тавышы туктарга мәҗбүр итте аны.

– Абый… Әйтмәм дигән идем инде… Ни… Әнә тегендә, өянке артында муеннарына бинокль аскан ике малайны күрәсеңме?.. Ие, ие, син гел маңгайларына «шалбан» биреп китәсең ди аларның… Кичә шулар белән дә бәхәсләшкән идем мин, «бармагымны төкреклән, Әфләтүневнең маңгаена ун тапкыр чиертәчәкмен» дип… Биш йөз сумга бәхәсләшкән идем, абый…

Әфләтүневнең тамак төбеннән «ыйк» дигән шөкәтсез тавыш чыкты, күзләре акайды, йодрыклары төйнәлде, ул ачуыннан көндәшенә ыргылды, әмма сипкелле малайдан җилләр искән иде инде.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 234

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+